# ИМАНЛЫ ГАИЛӘ

Гаилә тормышын яктыртучы дини-мәгърифәти газета

№2
АПРЕЛЬ
2012

Газетада Коръән аятьләре булу сәбәпле, саклык белән куллануыгызны сорыйбыз.


## АНОНС

*Гаилә—ул бер дәүләт.*

2 бит



Ташлама мине, Ходам!

3 бит



Иман җимешләре

4 бит

Рәшидә абыстай ИСХАКЫЙ:

**“Ир белән хатын арасында Иман торсын”**



6 бит



Иң бөеге—бала хакы



***“...Һичшиксез, ир белән хатынны бер-берсенә бәйләгән нәрсә—мәхәббәт. Өйләнешү—ир белән хатын арасындагы бер күпер булса, мәхәббәт күперне нык иткән кадакларга охшаш. Гаилә—бер таш бина булса, мәхәббәт аны беркеткән известькә охшаш. Мәхәббәт булган җиргә төзеклек һәм мәдәният килер, мәдәният булмаган җиргә һәлакәт килер. Мәхәббәт адәм баласын һәртөрле әшәкелекләрдән пакьләр. Иң теләнгән һәм иң кирәкле булган мәхәббәт—ул ир белән хатын арасындагы мәхәббәт. Мәхәббәт пакь һәм саф булганда гына ир белән хатынны бер-берсенә якын китерә, холыкларын төзәтә һәм акылларын тәрбияли. Ләкин мәхәббәт мәсьәләсендә ир белән хатын үзләре дә бер читтә булмыйча, сәбәпләренә керешергә тиешләр...”***

***Ризаэддин ФӘХРЕДДИН***



*Рәис хәзрәт МӨБАРӘКШИН*

# ИР БЕЛӘН ХАТЫН ХАКЫ

*Дәвамы. Башы үзган санда.*

—Ир белән хатын яратышканда, бер-берсенә карарга һәм тәннәренең бар әгъзаларына да кагылырга хаклы. Аларга якынлык кылырга рөхсәт ителгәч, кагылу-карау ничек тыелсын ди инде?! Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) белән хатыны Гайшәнең бер таздан юынулары да мәгълүм. Пәйгамбәребез (с.г.в.)дән: "Без гаурәтебезне кемнән яшерергә тиешбез?"—дип сораганнар. Ул: "Хатыннарыгыздан кала барлык кешедән дә яшерегез",—дип җавап кайтарган. Шуңа күрә ир белән хатынга бер-берсенең тәненә карарга һәм кагылырга ярый,—дип дәвам итте абыстай.

Фатыймага кинәт оят булып китте. "Әгәр абыстай мине шуның өчен генә килгән дип уйласа?.. Әгәр дә мине, Аллаһыдан курыккан булып кылана, яулык бөркәнсә дә тыйнак түгел икән бит бу хатын, дип уйласа?.."—дип кызарынып утырды ул. Абыстай шулкадәр акыллы хатын, ул инде мондый сөйләшүләрне бик күп алып барган һәм бүгенге сөйләшүдән дә бернинди нәтиҗә ясамый иде. Киресенчә, елмаеп, яшь хатынны эчкерсез сөйләшүгә җәлеп итәргә тырышты.

Тагын бераз сөйләшеп утыргач, Фатыйма китәргә җыенды. Чөнки абыстай олы яшьтә, "Аның кунакчыл булуыннан явызларча файдалану булыр бу",—дип фикер йөртте ул.

—Сезнең сүзләрне тизрәк иремә дә ирештерәсем килә,—дигән булып кайтып та китте.

Юлда аны: "Иремә ничек сөйләргә? Ничек аның ирлек горурлыгына кагылмый гына, үземнең хокукларны һәм иремнең бурычларын аңлатырга?"—дигән сорау бимазалады. Һәм... башына кызыклы бер фикер килде.

Бервакыт ул бер ирнең тарихы хакында ишеткән иде. Аның хәле башкача: ир хатынын ярата, ә менә хатыны аңа буйсынырга теләми. Ир үзе генә хәл итә алмагач, имам янына бара. Аның киңәшен тотып, ир, хатыны белән икесенең арасын җайлауга ирешә. Фатыйма да имам киңәшен кулланып карарга булды.

Фатыйма кич ирен эштән көтеп алды, ул гадәттәгечә соң кайтты. Хатын ирен ашатты, бергә кичке намазны укыганнан соң, Гали кулына китап алды, исәбе азрак укып алу иде. Фатыйма эше күп кеше кыяфәтен чыгарып, арлы-бирле йөренеп торды. Бераздан Галинең утны сүндергәнен күрде, тагын да сабыр итәргә тырышты хатын. Соңрак тәһарәт алды һәм намазлыгын җәеп төнге намазын укый башлады. Сәҗдәгә башын куйгач, чын ихластан Аллаһыдан иренең үзенә карата үзгәрүен, элеккечә назлы булуын сорады. Моны яшерен рәвештә эшләмәде ул, киресенчә, Галие ишетсен дип кычкырыбрак сорады. Чөнки бары Ул гына аңа ярдәм итә, иренең үзгәрүе дә бары Аңардан гына тора. Фатыйма моңа ихлас ышана һәм шулай булуын бик тели иде. Ашыкмады хатын, озаклап намазын укыды, җиренә җиткереп, күңелендә булган хис-кичерешләрен Аллаһыдан яшермичә әйтте. Хәтта бер мәлгә үзенең нинди максатта намазга басканын да онытып җибәргәндәй булды. Гали рәхәтләнеп йоклый иде... Фатыйманың йөрәге әрнесә дә, "Көнем бушка узмады",—дип юатты үзен. Галигә бераз карап торгач, хатын ире янәшәсенә ятып йоклап китте.

Икенче көнне дә бирешергә уйламады хатын, уйлаган карарын тормышка ашыру нияте белән эшкә кереште. Кичке намазга басты, әмма кичәге кебек озаклап маташмады. Гали дә кичәге кебек йокламады, аның әйләнептулганып ятканын ишетеп торды Фатыйма. Ир хатынының Аллаһыдан ни сорап ялварганын да ишетеп ятты.

Өченче көнгә Фатыйманың эченә корт керде. "Юкка өметләнәм, азапланам ахры",—дип уйлады ул. Бик теләми генә, өйрәнелгән гадәт буенча, намазлыгына басты хатын. Иренең аны аңламаганына, Аллаһы Тәгаләнең нигәдер аңа булышырга теләмәвенә борчыла иде ул.

—Йа Раббым! Нигә ул мине яратмый? Мин аны бик яратам бит,—дип елап җибәрде ул сәҗдәгә иелгәндә.

Кинәт көчле куллары белән ире кочаклаганын тоеп, сискәнеп китте Фатыйма. Галинең күзләре дә яшь белән тулган иде:

—Ни сөйлисең син? Мин дә сине бик яратам...—дип пышылдады ир...

*Дәвамы киләсе санда.*

## АПРЕЛЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Милади 2012 ел | Көн иseme | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы | Һиҗри 1433 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Якш | 04:44 | 06:14 | 12:48 | 13:02 | 17:15 | 19:22 | 20:52 | 10 | Җөмәд әл-әүвәл |
| 2 | Дүш | 04:41 | 06:11 | 12:48 | 13:02 | 17:17 | 19:24 | 20:54 | 11 | |
| 3 | Сиш | 04:38 | 06:08 | 12:47 | 13:02 | 17:18 | 19:26 | 20:56 | 12 | |
| 4 | Чәр | 04:36 | 06:06 | 12:47 | 13:02 | 17:19 | 19:28 | 20:58 | 13 | |
| 5 | Пән | 04:33 | 06:03 | 12:47 | 13:02 | 17:21 | 19:31 | 21:01 | 14 | |
| 6 | Җом | 04:31 | 06:01 | 12:46 | 13:02 | 17:23 | 19:33 | 21:03 | 15 | |
| 7 | Шим | 04:28 | 05:58 | 12:46 | 13:02 | 17:24 | 19:35 | 21:05 | 16 | |
| 8 | Якш | 04:26 | 05:56 | 12:46 | 13:02 | 17:25 | 19:37 | 21:07 | 17 | |
| 9 | Дүш | 04:23 | 05:53 | 12:46 | 13:02 | 17:27 | 19:39 | 21:09 | 18 | |
| 10 | Сиш | 04:21 | 05:51 | 12:45 | 13:02 | 17:28 | 19:41 | 21:11 | 19 | |
| 11 | Чәр | 04:18 | 05:48 | 12:45 | 13:02 | 17:29 | 19:43 | 21:13 | 20 | |
| 12 | Пән | 04:16 | 05:46 | 12:45 | 13:02 | 17:31 | 19:45 | 21:15 | 21 | |
| 13 | Җом | 04:13 | 05:43 | 12:45 | 13:02 | 17:32 | 19:47 | 21:17 | 22 | |
| 14 | Шим | 04:11 | 05:41 | 12:44 | 13:02 | 17:33 | 19:49 | 21:19 | 23 | |
| 15 | Якш | 04:08 | 05:38 | 12:44 | 13:02 | 17:35 | 19:51 | 21:21 | 24 | |
| 16 | Дүш | 04:06 | 05:36 | 12:44 | 13:02 | 17:36 | 19:53 | 21:23 | 25 | |
| 17 | Сиш | 04:03 | 05:33 | 12:44 | 13:02 | 17:37 | 19:55 | 21:25 | 26 | |
| 18 | Чәр | 04:01 | 05:51 | 12:43 | 13:02 | 17:39 | 19:57 | 21:27 | 27 | |
| 19 | Пән | 03:58 | 05:28 | 12:43 | 13:02 | 17:40 | 19:59 | 21:29 | 28 | |
| 20 | Җом | 03:56 | 05:26 | 12:43 | 13:02 | 17:41 | 20:01 | 21:31 | 29 | |
| 21 | Шим | 03:53 | 05:23 | 12:43 | 13:02 | 17:43 | 20:03 | 21:33 | 30 | |
| 22 | Якш | 03:51 | 05:21 | 12:42 | 13:02 | 17:44 | 20:05 | 21:35 | 1 | |
| 23 | Дүш | 03:49 | 05:19 | 12:42 | 13:02 | 17:45 | 20:07 | 21:37 | 2 | Җөмәд әл-ахир |
| 24 | Сиш | 03:46 | 05:16 | 12:42 | 13:02 | 17:47 | 20:09 | 21:39 | 3 | |
| 25 | Чәр | 03:44 | 05:14 | 12:42 | 13:02 | 17:48 | 20:11 | 21:41 | 4 | |
| 26 | Пән | 03:41 | 05:11 | 12:42 | 13:02 | 17:49 | 20:13 | 21:43 | 5 | |
| 27 | Җом | 03:39 | 05:09 | 12:42 | 13:02 | 17:50 | 20:14 | 21:44 | 6 | |
| 28 | Шим | 03:37 | 05:07 | 12:41 | 13:02 | 17:51 | 20:16 | 21:46 | 7 | |
| 29 | Якш | 03:34 | 05:04 | 12:41 | 13:02 | 17:53 | 20:18 | 21:48 | 8 | |
| 30 | Дүш | 03:32 | 05:02 | 12:41 | 13:02 | 17:54 | 20:20 | 21:50 | 9 | |

## *Ташлама мине, Ходам!*



Бар минем балачактан
Яратып кылган догам:
Әти-әни бәхетеннән
Аерма мине, Ходам!

Үземне дә ялгыз итмә,
Пар канат сорап калам.
Догаларым кабул булсын,
Ташлама мине, Ходам!


Бала бәхетен күрергә
Насыйп ит миңа, Ходам!
Кабул булсын иде инде
Ялварып кылган догам.

"Әлхәм" белән "Колхуалла"—
Яратып кылган догам.
Һәм намазлык өсләрендә
Сәҗдәдә кылган догам.
Барлыгына ышанамын—
Ташламас әле Ходам.

**Газизә БУЛАТОВА**

***Адәм баласы кайчан иманга килеп, Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген таный, Аның тыйганнарыннан тыелып, Ул кушканча яши башлый, шул чакта гына бәхетле була. Шуннан ул кеше бәхетенең ни икәнен аңлый башлый, бу дөньяда һәм ахирәттә Аллаһының рәхмәтенә ирешә.***

# ИМАН ҖИМЕШЛӘРЕ



Аллаһы Тәгаләгә иман китерүнең нинди өстенлекләре бар соң? Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

**1. “Үземә ышанганнарны дөрес юлдан җибәрермен”,—ди. “Хаҗ” сүрәсенең 54нче аятендә бу хакта: “Шик юк ки, Аллаһ иманлы булырга теләгәннәрне тугры юлга юнәлтер”,—диелә.**

Кеше хайваннан акылы һәм уйлый белүе белән аерыла. Тик әле бу дөньяда дөрес яшәү өчен акыл гына җитми. Акыл бит әле ул тиеш булмаган карар кабул итеп, ялгышырга да мөмкин. Аллаһы Тәгалә кешегә күрү мөмкинлеге биргән—Аның тарафыннан бу искиткеч зур бүләк! Кеше күзләре белән яхшырак күрсен өчен, яктылык та биргән ул. Яктылык булмаса, без берни күрә алмас идек. Менә шуның кебек, дөрес яши алсыннар, дөрес юлдан барсыннар дип, Аллаһы Тәгалә кешелеккә Коръән иңдергән. Бу хакта Аллаһы Тәгалә “Ниса” сүрәсенең 174-175нче аятьләрендә әйтә: “Әй, бәндәләр, шөбһәсез ки, сезгә Раббыгыздан катгыян бер дәлил килде вә сезгә ап-ачык бер нур (Коръән) иңдерелде. Аллаһка иман китереп, Аның диненә нык тотынганнарны рәхмәтеннән аермас һәм аларны мул итеп бүләкләр вә аларны тугры юлдан—Үз тарафына җибәрер”.

Коръән кешене яхшыны яманнан, дөреслекне ялганнан, шәфкатьлелекне явызлыктан аерырга өйрәтә. Коръәннең бер аятендә: “Миннән сезгә күрсәтмә килер, кем минем өндәмәләремә иярә, шул тугры юлдан чыкмас вә бәхетсез булмас”,—дип әйтелә (“Та-һа” сүрәсе: 123нче аять). “Күрсәтмә” дигәнне Коръән китабы дип аңларга кирәк. Коръән бу дөньяны дөрес итеп аңларга, катлаулы хәлләрдән дөрес итеп чыгу юлларын да күрсәтә. Кеше ялгышмый тормый, ялгыша. Шул чакта ул Коръән китабын кулына алып укыса, бөтен сорауларга да җавап таба ала.

Хәзер шайтан коткысына ияреп, кеше милкен тартып алу, риба, әтиәнине тыңламау, хәмер куллану, тәмәке тарту, наркомания, никахсыз яшәү, бер җенеслеләрнең гаилә коруы кебек ямьсез күренешләр киң колач алды. Боларның барысы да Аллаһыны танымаудан, Коръәнне белмәүдән килә. “Бәкара” сүрәсенең 38нче аятендә: “Әгәр дә сезгә Миннән күрсәтмәләр-өндәмәләр килсә, минем күрсәтмәләремә тугры булганнарга куркыныч янамас вә алар хәсрәт чикмәс”,—диелгән. Коръән кушканча яшәгән кеше киләчәге өчен хафаланмый һәм үткәннәре өчен үкенми. Чөнки андый кешенең иманы нык була һәм авырлыкларны да сабыр итеп уздыра ала.

**2. Матур тормыш.**

“Нәхел” сүрәсенең 97нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә: “Ир кешеме ул, хатынмы, мөселман булып, игелекле эшләр башкарса, аларны, һичшиксез, матур тормышта яшәтәчәкбез. Һәм әҗерләрен дә кылган иң игелекле эшләре буенча бирербез”,—ди. “Матур тормыш” дигәненә барысы да—синең тормыш хәлең дә, сәламәтлегең дә, яшәү рәвешең дә, кылган изгелекләрең дә керә. Әгәр адәм баласы туры юлдан читкә тайпылса, Аллаһы Тәгаләнең кисәтүләреннән йөз чөерсә, “Та-һа” сүрәсенең 124нче аятендә әйтелгәнчә, “Һичшиксез, аның тормышы газаплы булачак һәм Без аны Кыямәт көнендә тома сукыр килеш кабереннән кубарачакбыз”. Менә нинди хәлләр көтә!

Коръән кушканча яшәмәгән кешене Аллаһы Тәгалә күңелсез тормышта яшәтәчәк. Кеше бай булырга, җәмгыятьтә югары дәрәҗәгә ирешергә мөмкин, тик аның җаны тыныч булмаячак. Аллаһы Тәгалә андый кешегә һәрьяклап борчу китерә—балалар, милек, эш һ.б. Ул һәрвакыт шул проблемалары хакында гына уйлап, җанына тынычлык тапмый яшәячәк. Өстәвенә, аны Кыямәт көнендә сукыр килеш кабереннән кубарылу да көтә.

**3. Матур язмыш.**

Аллаһы Тәгалә Үзенә ышанган һәм Аның кисәтүләреннән курыккан кешеләргә матур язмыш бүләк итә.

“Бу илләрнең халыклары иман китереп, гөнаһтан курыккан булсалар иде, әлбәттә, аларның өстенә Күктән, Җирдән мул бәрәкәт капкаларын ачкан булыр идек. Ләкин алар Аллаһның аятьләрен инкарь иттеләр. Без дә кылган көферлекләренә күрә, аларны каргышка тоттык.” (“Әгъраф” сүрәсе: 96нчы аять.)

Әгәр җир шарындагы бар кеше иманга килеп, Коръән кануннары буенча яши башласа, Аллаһ аларга һәр нәрсәдә бәрәкәт бирәчәк. Һәр кеше муллыкта һәм тынычлыкта яши башлар иде.

**4. Аллаһы Тәгалә иманлы кешегә дошманнарына каршы көрәшкәндә ярдәм итә.**

Аллаһы Тәгалә “Рум” сүрәсенең 47нче аятендә: “Мөэминнәргә ярдәм итү—Безнең эш”,—ди. Аллаһы Тәгалә мөселманга дошманын җиңәргә ярдәм итә. “Мөхәммәд” сүрәсенең 7нче аятендә Аллаһы Тәгалә болай ди: “Һәй, иман китергән кешеләр, әгәр сез Аллаһка буйсынып, ярдәм итсәгез, Ул да сезгә ярдәм итәр вә тез буыннарыгызны нығытыр”. Монда сүз кулга көсәк алып яки корал тотып дошманыңны кыйнау яки үтерү турында бармый. Аятьнең мәгънәсе шул: әгәр дә син Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп яшәсәң, дин тотсаң, дошманыңнан Аллаһы Тәгалә тарафыннан якланачаксың. Ашыйсың килсә—эшләргә, галим булырга теләсәң, укырга кирәк булган кебек, Аллаһының ярдәм итүен теләсәң, Аңа ышанырга һәм Ислам дине кануннары буенча яшәргә тиеш буласың.

**5. Аллаһы Тәгалә иманлы бәндәләрне саклый.**

Аллаһы Тәгалә “Хаҗ” сүрәсенең 38нче аятендә: “Аллаһ иманлыларны саклар. Шунысы да хактыр ки, Аллаһ хаин вә кяфер һәр кешене мәхәббәтеннән мәхрүм итәр”. Аллаһы Тәгалә хак мөселман булган бәндәне төрле җәберзолымнардан саклый.

Аллаһы Тәгаләгә якынаю Адәм баласы өчен иң олы бәхет икәнен аңласак иде. Аллаһы Тәгаләнең: “Иман китереп, игелек кылганнарга ярлыкау вә мул ризык булыр”,—дигән вәгъдәсе бар, Ул беркайчан вәгъдәсен бозмый. Һәрбер кылган гамәлебез Аллаһ ризалыгы өчен булырга тиеш. Аллаһының Үзен дә, фарызларын да, хәрәм дигән әйберләрен дә инкарь итәргә ярамый.

**6. Яхшы үлем.**

Аллаһы Тәгаләгә ышанган һәм Аның кушканнарын үтәп яшәгән кешене үлем якынлашканда фәрештәләр тынычландырачак.

“—Хактыр ки, Раббыбыз—Аллаһ,—дип тугры юлга басканнар янына фәрештәләр иңәр.

—Курыкмагыз, хафаланмагыз, куанызыз: сез алдан ук вәгъдә ителгән җәннәткә керәчәксез,—дип сөенче алырлар.” (“Фуссиләт” сүрәсе: 30нчы аять)

Һәркайсыбызга Аллаһ Раббыбыз хәерле гомерләр биреп, Үзенең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәүләребезне, әҗерен шушы дөньяда да күрүебезне һәм бу вакытлы дөньядан мәңгелеккә иман әһеле булып күчеп, Аллаһының җәннәтендә булуларны насыйп итсә иде.

**Алмаз хәзрәт САФИН**



# Рәшидә абыстай ИСХАКЫЙ: “ИР БЕЛӘН ХАТЫН АРАСЫНДА ИМАН ТОРСЫН”

**Кеше ни өчен дөньяга килә? Яшәүнең мәгънәсе нидә? Ана карынында ук баланы ничек дөрес итеп тәрбияләп була? Ничек итеп балада дингә мәхәббәт уятырга мөмкин? Шушылар хакында уйлап, фикерләп яшәүчеләр өчен Рәшидә абыстай Исхакыйның тормыш юлы—искиткеч камил үрнәк!**

Кечкенә вакыттан ук әти-әнисе биргән дини тормыш сукмагыннан атлаган кыз бүгенге көндә—халык арасында танылу алган, мактаулы абыстай, халыкны Коръән серләренә төшендерүче, намазга өндәп өйрәтүче мөгаллим. Ул бүген:

*“Йа, Аллаһым! Мең, мең*
*рәхмәт Сиңа.*
*Бәрәкәтле гомер биргәнсең.*
*“Тугры юлдан атла,*
*гафиллектә ятма,*
*Игелек кыл, бәндәм”,—дигәнсең”,—*

дип, узган гомеренә шөкер итеп, Раббысына рәхмәт укый. Ә узган гомергә күз салсаң... Анда ниләр генә юк!

1924 елда ишле гаиләдә унынчы бала булып дөньяга килә ул. 4 яшендә апасы Бибисара тегеп биргән күлмәген киеп: “Минем дүрт күлмәгем бар: бәрелгән, бозган, тузган, тегәсе күлмәгем”,—дип мактана. Шул вакытта ук аның күңелендә аз әйбергә дә күп итеп куана белү булган ахры. 8 яшендә мәктәпкә укырга кергәндә, намаз укый башлаган була инде ул. Аларны әти-әниләре Пәйгамбәрләр тарихы белән таныштырып, Аллаһының боерыкларын танытып һәм хезмәткә өйрәтеп үстерәләр. Хәтта өй юу кебек авыр эшләрне эшләгәндә дә,тәһарәтләндереп, намазларын вакытында укыта. Кызлары: “Әни, өйне юып бетергәч укырбыз”,—дисәләр: “Ник өегез дөрләп янмый, мин сезгә намаз калдыртаммы?”—дия торган була. Шуңа күрәдерме, намазны укырга өйрәтү, аның кирәклеген, мәгънәсен төшендерүгә бик күп көчен куя Рәшидә абыстай. “Намаз укый башлаган кешенең көнегез—туган көнегез була”,—дип үгетли ул башкаларны. Тик аның бу гамәлләре баштарак, дин тыелган вакытларда күпләргә ошап та бетми. “Рәшидә кеше җыеп дин укыта”,—дип, “тиешле” урынга шалтыратучылар да була. “Мулла Рәшидә”не эзләп өенә килгәч: “Төрмәгә утыртабыз, туктат бу эшеңне”,—дип өркетергә маташалар аны. Курыкса да, калтырап төшми ул: “Ябыгыз, төрмәдә дә наданнар күп, анда да укытырмын”,—дип җавап бирә. Күпләрне, бик күпләрне Аллаһ кушканча яшәргә өйрәтә Рәшидә абыстай. Һәй, нигә сөйләп торырга, аның намаз укырга өйрәтүче китабы күпме кешене намаз иясе итте икән?! Ә балалары?! Балалары, аларның балалары, аларының да балалары—җәмгысы 106 бала һәм аларның барысы да намаз иясе! Искиткеч хәл бит бу! Балаларына бернинди “ташлама” ясамаган Рәшидә абыстай. Үзе әйтмешли, “берсенең бер намазы калса, алтысын да тотып кискән”. Һәм менә сезгә нәтиҗә—балалар иманлы, алардан туган балалар тәүфыйклы, оныкларның балалары да Рәшидә абыстайның куанычы булып динне белеп, аңлап үсәләр. Балаларына карата булган таләпчәнлегенең матур нәтиҗәсе бу. “Намаз—мөэминнең нуры. Йөрәк бәгыремнән чыгарып әйтәм бу сүзләрне. Динсез кеше—ахмак. Укыгыз, өйрәнегез, гыйбадәттә булыгыз, иманыгызны ныгытыгыз. Гыйлемне күтәреп йөрисе юк, ул үзегез белән, ак яулыклы ачык йөзегез белән, изге ниятләрегез, изге гамәлләрегез белән”,—ди Рәшидә абыстай. Шигырьләрендә:

*“Куәт бир син хикмәт юлыннан*
*барырга,*
*Гакыллы колларның күңелләрен*
*баетырга.*
*Мөслимәнең хакы ни икәнен сөйләп,*
*Бәндәләргә аңлатырга”,*—дип язган

Рәшидә абыстайга 1975 елдан бирле шул эшләр белән шөгыльләнергә мөмкинчелек бирә Аллаһы Тәгалә. “Мин вафат булгач, бәндәләр шул вәгазьләрдән файдаланып, иманга күңелен биреп, бәхетле булып яшәп, бәхетле булып үссеннәр иде”,—дигән ният белән кассеталар, дисклар яздыра.

И хатын-кыз! Бу дөньяның йөзек кашы бит ул! Берничек тә бәһа җитмәслек иң кыйммәтле асылташы да! Кайлардан көч ала икән ул тормыш дилбегәсен ирләрдән ныграк тартырга, балалар үстерергә, барысын да гафу итәргә, кичерергә йөрәге ничек түзә икән?

**—Гаилә хакында сүз чыкса, авырлыкның күбрәк хатын-кыз җилкәсенә төшкәнен аңлыйсың. Бу шулай тиешме соң, Рәшидә абыстай?**

—“Ирләр—башлап йөрүчеләр”,—ди Аллаһы Тәгалә. Әмма, ир янында иманлы хатын булу кирәк. Әгәр шундый хатын туры килсә, гаиләне тигез итеп тартып алып бара белерләр. Әгәр инде иманы зәгыйфь хатын туры килә икән, Аллаһ сакласын берүк, иманын суырып бетерәчәк ул ирнең! Әти: “Без әниегез белән икебез дин юлында булгач, Аллаһы Тәгаләне олылап яшәгән өчен Ул безгә иманлы балалар бирде”,—дип әйтә торган иде. Үзем дә хәрәм ашамадым, балаларымны иманлы итеп тәрбияләргә тырыштым. Кияүгә чыкканның икенче көнендә үк ирем Гомәрне дә намазга бастырдым. Гомерем буе гыйбадәттә булдым, балаларга бисмилласыз ризык каптырмадым. Балаларымны Ислам дине белән тәрбияләп үстергән өчен Аллаһы Тәгалә миңа бәрәкәтле гомер бирде. Менә шуңа күрә, ир кеше янында иманлы хатын булу кирәк. Ир кешенең хатын җилкәсенә авырлыкны өймичә, тормышны тартып алып бара белүе дә мөһим. Ир алып кайткан малны бәрәкәтле итеп тота белгән хатын мактаулы санала. Халыкка иманлы бала тәрбияләүне өйрәтергә кирәк. Хәрәм ашамыйча, Ислам дине кушканча вакытында биш вакыт намазын укыса, балалар тәүфыйклы, илләребез-өйләребез тыныч була, ата-ана Аллаһының рәхмәтенә юлыга.

**—Гаиләне ничек сакларга дигән чакта, киңәш бирүчеләр, аеруча басым ясап, хатын-кызларның гына бурычларын саный башлыйлар. Гаиләне саклауда ирләрнең роле шулкадәр түбән дәрәҗәдәмени?**

—Ирләр өйдә хуҗа булырга тиеш. Алар эшләргә, мал табарга, гаиләнең бөтенлеген кайгыртырга тиеш. Ә хатын-кыз өйнең учагын сүндермичә, малның бәрәкәтен арттырып, ашарга әзерләп, бала тәрбияләп торырга тиеш. Әүвәл Аллаһының әмерен үтәсен хатын-кыз, аннан соң ир хакын хакласын. Ирне яхшылыкка өндәсен ул, әгәр ир яманлыкка өндәүче икән, хатын-кызның андый ирне тыңларга хакы юк. Исерек булса, динсез булса, андый ирне санлап булмый. Шуңа күрә хәзер хатын-кызларыбыз хуҗа булып киттеләр. Ирләребез әхлаклы, динле

түгел, Аллаһ әмерендә раст түгелләр. Алар хатыннарын, балаларын, йорт-җирләрен карап-барлап торырга, хуҗа булырга тиешләр.

**—Хатын-кыз иренең хыянәтен ничек кабул итәргә тиеш?**

—Акыл белән кабул итәргә һәм сабыр булырга тиеш. Акыллы хатын хыянәт иткән иренә: "Аллаһы Тәгалә бу эшеңә разый булмас. Балаларыбыз ятим була бит. Әйдә, бу эшеңне ташла",—дип, ирне үгетләргә тиешле. Аллаһы Тәгаләнең иң яратмаган нәрсәсе—аерылышу, талак. Балаларым Аллаһы Тәгалә кушканча яшәгәнгә, андый гамәлләре булмады, әлхәмдулиллаһ. Барысы да Ислам балалары, әлфәт мәхәббәт белән яшиләр.

**—Кайбер ирләргә дә хыянәт ачысын татырга туры килә. Алар бу очракта үзләрен ничек тотарга тиеш?**

—Андый хәлләр дә була. Хатын-кыз хыянәте булса, акыллы ир аны сынап йөрергә дә, аңлатырга, "Кадерлем, бу—Аллаһ кушканча түгел. Болай итеп балалар тәрбияләп булмый",—дип яхшылап әйтергә тиеш. Бер-ике тапкыр шулай әйтеп тә аңламаса, ирнең андый хатынга талак кылуы да мөмкин эш.

**—Сәбәпсез көнләшүче ирләр белән ничек яшәргә? Өйдәге изелүгә түзеп яшәүче хатын-кызлар дөрес эшлиме?**

—Хатын-кыз андый иргә сабыр итеп яшәргә тиеш. Башкача мөмкин түгел. Әгәр ул намазлы, иманлы икән, аның характерын өйрәнеп-төшенеп яшәргә кирәк. Инде ул Аллаһыдан ерак икән, имансыз, намазсыз, тәһарәтсез икән, бер дә сабыр итү, түзү мөмкин булмаса, казый белән киңәшеп эш итәргә кирәк. Ул ни дип әйтсә, шулай була. Андый хәлләр миңа очрамады, әлхәмдулиллаһ. Балаларым бергә бардылар, бер белән яшиләр, һәрберсеннән яхшы хәбәр килеп тора. Ниятебез яхшы булгач, башта үзем читкә тараткан балаларымны Аллаһы Тәгалә кабат Казанга җыйды.

**—Сезнең гаилә ничек барлыкка килде, Рәшидә абыстай? Ничек яшәдегез?**

—Иманлы кешегә кияүгә чыккан идем мин. Ике ел бик яхшы яшәгән дә идек. Саклык кассасы җитәкчесе булып эшли иде ирем. 1947 елгы реформа вакытында, халыкка яхшылык эшләве сәбәпле, 16 елга төрмәгә яптылар. Төрмәдә дә намазын калдырмады ул. Аллаһының кодрәте белән, тоткынлык вакытын дүрт елга калдыруга ирешкән идек. Акланып кайтып, ике ай гына яши алды, үлеп китте. Балаларыбыз булмау сәбәпле, ялгыз калдым. Ирем белән төрмәдә бергә утырган Гомәр атлы кешегә кияүгә чыктым. "Бала тапмый торган хатын" булып кабат кияүгә чыккан идем, Аллаһы Тәгалә миңа алты бала бүләк итте! Аллаһ юлында булганым, сабыр иткәнем өчен миңа шушы матур тормышны бирде Аллаһы Тәгалә.

**—Тормышыгызда булган берәр гыйбрәтле хәл хакында сөйләгез әле.**

—Әтиемне "кулак" дип төрмәгә яптылар, 12 балага берни калдырмый тәэп алып чыгып киттеләр. Ашарга, өскә кияргә кием юк, авырлыкларны бик күп күрдек. Урман кисеп, окоп казып йөрдем. Колхозда берьюлы 6-7 эштә эшләдем. Шулай булса да, телем зекер әйтүдән туктамады, хәрәм ашамадым. Мин бүген бик бәхетле әни. Миннән дә бәхетле кеше бармы икән бу Казан каласында?! Госманым машина алып бирде, киявем мине йөртә. Әле бит һаман да укытам. Укыта башлавыма 40 ел, әлхәмдулиллаһ, быел да өч группа укытам әле. Киявем кая барасым булса да алып бара. Тегесе килеп хәлне белә, монысы килеп күчтәнәч алып керә, менә нинди бәхетле кеше мин. Олы кызым-киявем белән яшим. Олы кызымны Ташкент шәһәренә намазлы егеткә биреп җибәргән идем, Казанга 20 булып кайттылар. Барысы да иманлы, намазлы, уразалы, исемнәре матур, тормышлары яхшы.



*Рәшидә абыстайның Татарстанның элекке мөфтие Госман хәзрәт Исхакыйның әнисе икәнлеген барыбыз да белә. Бер әңгәмә вакытында Госман хәзрәт болай дигән иде:*

*—Миннән: "Дингә кайчан килдең?"—дип сорыйлар. "Диннән китеп торганым булмады",—дип җавап бирдем. Мин—бик бәхетле кеше. Минем әнием кебек әни җир йөзендә бераү генә. Дингә мәхәббәтем иң беренче Аллаһыдан булса, икенчесе—әниемнән. Мин аңа моның өчен үлгәнче рәхмәтле. Алты баласын да намаз укымыйча ашатмаган, йоклатмаган кеше ул.*

*Мин мөфти булганчы, Минтимер Шәймиев мине белмәсә дә, әниемне яхшы белә иде.*

*Әни кеше өчен бала авызыннан мондый сүзләр ишетү нинди олы бәхет!*

**—Гаиләне ничек сакларга?**

—Аллаһы Тәгалә кушканча яшәргә, әхлаклы, түземле булырга кирәк. Ир яки хатынның берәрсе бозык юлдан кереп китсә, тизрәк аерылышып куйганчы, бер-береңне Аллаһ юлына өндәү зарур. Ир белән хатын арасында Иман торсын, ике арага башка нәрсә керергә тиеш түгел. Миңа өйләнгәндә, икенче ирем беренчесе кебек динле кеше түгел иде. Минем белән яшәү дәверендә дин юлына басып, гаиләбезгә имам булып тору дәрәҗәсенә күтәрелде ул.

Үзем Рәшидә абыстайны тыңлыйм, үземне ирексездән уйларым читкә тарта. Нинди кеше икән бу, ак яулыклы, нурлы йөзле, 90 яшькә якынлашса да мәһабәтлеген җуймаган, хәрәкәтчән, гап-гади татар әбисе, хөрмәтле Ана! Шушының кадәр изге гамәлләрне башкарып чыгар өчен каян көч ала ул? Өстәвенә, бу хезмәтләрнең барысы да бушка бит. Күрәсең, Аллаһы Тәгалә бу кешеләргә туганда ук шундый язмыш язадыр, шундый гайре табигый олы йөрәк, камил акыл, зирәк зиһен бирәдер. 11-12 яшьләрендә күргән хикмәтле төше дә моңа дәлил түгелме соң?


—Бервакыт 11-12 яшемдә төш күрәм: болытсыз, аяз күк. Якты кояш. Яңгыр ява. Шул яңгыр астында көтү көтәм. Бу төшне күреп, тәрәзә төбендә уйланып утырдым да, әнигә сөйләдем. Әни: "Кызым, бик хикмәтле төш күргәнсең. Ил өстендә олуг булырсың, Ислам тәрбиясе бирерсең",—дип юрады. Ул вакытта мин гарәпчә укый да, яза да белми идем әле...—дип сөйләде ул.

*"Хак дин—Ислам дине генә,*
*Тынычлык бирә безгә.*
*Ислам канунын белеп,*
*Нур бирик илебезгә"*,—дип язуы да юкка түгел Рәшидә абыстайның.

Ул чын ихластан Ислам диненең алга китүен, исерекләр-башкисәрләр, зиначылар булмавын, һәркемнең Аллаһының канунын белүен тели. "Балаларыбызга кече яшьтән дин тәрбиясен бирик",—дип тырыша. "Илебез тыныч булыр, тыныч илдә, тыныч өйдә тыныч яшәп, йөзләребезгә нур тулыр",—дип өметләнә.

Тырышлыкларының нәтиҗәсен күрергә, өметләренең кабул булуын, теләкләренең үтәлүен күрергә насыйп булсын Рәшидә абыстайга. 90 яше тулган көннәрендә дә күңеле тыныч булып, йөзеннән бәхет нуры ташып торсын.

**Лилия ГАЛИЕВА**






*Сорауларга Мөхәммәд хәзрәт МИФТАХОВ җавап бирә.*

**“Бекон тәме килгән ризыкны ашарга ярыймы?”**

—Сәбәп тәмдә түгел, ә ризык составындагы дуңгыз ите, яки шәригать кануннары буенча суелмаган хайван ите тыелган булуда. Әгәр андый тәм төрле химик юллар белән ясалып, җитештергәндә тыелган хайван ите кулланылмый икән, мондый ризыкны ашарга ярый.



*Сорауларга адвокат Руслан НАГИЕВ җавап бирә.*

**“Әгәр кулында чек булмаса, кулланучы товарны сатучыга кире кайтара аламы?”**

—Товарны нәкъ шул сатучыдан алуың хакында шаһитләрнең күрсәтмәләре буенча да, товар документлары (гарантия талоны, техник паспорт, ярлыклар һ.б.) белән дә исбатларга була.

Россия Федерациясенең “Кулланучылар хокукларын яклау турындагы” Законының 18нче маддәсе, 5нче пунктында әйтелгәнчә, кулланучыда товарны сатып алу фактын һәм шартларын раслаган касса яки товар чегы булмау, аның таләпләрен канәгатьләндермәүгә нигез түгел.

**“Багучыга бару кешене Ислам диненнән чыгарамы?”**

—Күрәзәчеләргә, багучыларга мөрәҗәгать иткән кеше Аллаһы Тәгаләгә түгел, Ул булдырганга таяна. Бу дөрес түгел. Андый кеше үзен күпаллалыкка ышанучы, мәҗүси булу куркынычы астына куя.

Хәдисләрдән билгеле булганча, күрәзәчегә барып, аннан нәрсә турында булса да сораучының кырык көн буе намазы кабул булмаячак.

**“Пирсинг тагу рөхсәт ителәме?”**

—Пирсинг, тәнгә рәсем төшерү билгеле бер төркем кешеләренә—рэпер, рокер, металлистларга хас. Болай эшләү, билгеле, әлеге төркемнәргә охшарга тырышу булачак. Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Кайсы да булса халыкка охшарга тырышкан кеше шул халыктан булыр”,—дигән. Димәк, әлеге гамәл рөхсәт ителми.

**“Улыбызны 1 класска укырга кертергә җыенабыз. Күптән түгел гариза яздык. Мәктәпкә керер өчен, булачак 1 класс укучыларына түләүле әзерлек курсларына йөрү мәҗбүри икәнлегең искәрттеләр. Бу дөресме? Әгәр улыбыз әзерлек курсларына йөрмәсә, әлеге мәктәпкә алмаска хаклары бармы? Ул яза да, укый да белә. Җитәкчелек: “Бала математиканы да белергә тиеш”,—ди. Безгә нинди дә булса өстәмә тест утуне оештыра алалармы?”**

—Бала математиканы белергә тиеш түгел. Мәктәпкә керер өчен хәтта укый белү дә мәҗбүри түгел. Башлангыч класс программасына язарга, укырга һәм мәктәп өчен кирәкле башка күнекмәләргә өйрәтү керә. Әгәр мәктәп уставында өстәмә түләүле хезмәт күрсәтү мөмкинлеге барлыгы турында пункт билгеләнгән икән, мәктәпнең әзерлек курслары оештырырга хакы бар. Тик бала мәктәпкә әлеге курсларның нәтиҗәсе буенча гына кабул ителми. Укырга кергәндә өстенлек мәктәп урнашкан микрорайонда яшәүче балаларга бирелә.




**Рәйсә абыстай ЗАРИПОВА,**
**Татарстан мөселманнар берлегенең Балтач бүлеге җитәкчесе**

—Ислам—буйсыну дигән сүз. Һәркем, нинди милләт кешесе булуына карамастан, Аллаһка буйсынырга тиеш. Кемдер моны олы яшькә җиткәч аңлый, гаиләдә күреп, балачактан ук аңлап үсүчеләр дә бар.

Хатын-кызларның күбесе: “Яулык бәйләсәм, мине эштән куалар”,—дип куркып яланбаш йөри. Курыкмагыз, кусалар да эшсез калмассыз! Бәлки әле хәерлегә генә булыр, тагын да яхшырак эшкә урнашырсыз. Аллаһы Тәгалә үзенә якынайганнарны авырлыкта калдырмый, барыбер күтәрә, җиңеләйтә бирә.

Бала тугач, әти-әниләре “булдырдык” дип мактанышып йөри. “Әлхәмдүлилләһ, Аллаһ бирде”,—димиләр, көфер сүз әйтәләр. Бала тугач, аракы эчеп “тәпи юып” утырмаска, ә корбан чалып, табын корып кунак итәргә кирәк. Ата-ана: “Балаларыбызны Аллаһ бирде. Ул алачак та. Аның каршына барып басарлык иманлы балалар үстерә алсак иде”,—дип, дер калтырап торырга тиеш.

Эш урынын саклап калу максатыннан, яшь әниләр 9-10 айлык балаларын яслегә бирәләр. “Акча кирәк”,—дип акланалар. Анда 25 балага бер тәрбияче, ул өлгерәме аларның барысын да тиешенчә карарга? Юк, билгеле! Менә шуннан башлана да инде, иммунитет төшә. Андый бала бөтен авыруны да тиз йоктыра, еш авырый. Ана баласын 4-5 яшькә кадәр үзе тәрбияләргә тиеш! Хатын-кыз иң беренче чиратта гаилә өчен тырышырга, баланың сәламәтлеге өчен кайгырырга тиеш!

*Әти-әниләргә*

# Иң беренче— бала хакы



**Ризаэддин ФӘХРЕДДИН:**

***“Ир кешегә гаиләнең җитәкчесе, ә хатын кешегә гаиләнең терәге һәм өй белән идарә итү вазифасы йөкләнелә”,—дип яза. Менә шуңа күрә дә инде, шәхес тәрбияләү эшендә хатын-кызга гаять зур урын бирелә. Хәтта милләт язмышы кадәр зур төшенчәнең дә турыдан-туры хатын-кызга бәйле булуына ишарәләп, галим: “Хатыннары тәртипле булган милләт—тәртипле милләт, хатыннары тәртипсез булган милләт—тәртипсез милләт...”—дип искәртә һәм җәмгыятьнең киләчәге—аналарның үз балаларын ничек итеп тәрбияләүләренә бәйле икәнлеген күрсәтә.***

Хатыннарның иң төп вазифасы һәм иң изге бурычы итеп, Ризаэддин Фәхреддин җәмгыятькә һәрьяктан лаеклы, югары әхлаклы, эчке мәдәниятле, һәркемгә бөтен яктан үрнәк булырлык шәхесләр тәрбияләү икәнлеген ассызыклый. Баланы тел белән тәрбияләү өстенә, үзеңнең шәхси үрнәгең белән дә тәрбияләргә, сүзең белән гаиләңне бертөрле алып барырга кирәклеген искәртә.

Р. Фәхреддин күзәтүенчә, бала 5-6 яшьләреннән узгач күзенә күренгән, акылы ирешкән нәрсәләрне сорашырга, һәр белгән нәрсәнең нигезен тикшерергә тотына. Аларның тикшерүләре бик укымышлы хокук галимнәрен дә хәйран калдырырлык гүзәл һәм кирәкле маддәләр турында була... Әгәр балаларның сорауларына иренмичә, ачык һәм дөрес, белеп җавап бирүче булса, никадәр генә сабый булсалар да, алар мәктәпкә барганчы ук бөек мәгърифәткә ирешүгә һәм зиһеннәренә гыйлем орлыклары чәчәргә яраклы булыр. Аларны бик арытмыйча, ялыктырмыйча гына, төрле уеннар арасында, алар кабул итәрлек рәвештә генә төрле әңгәмәләр корып, иләп кенә берсеннән-берсе кызыклы мәгълүматлар бирә башларга мөмкин.

Ризаэддин Фәхреддин: “Бөек хакларның да иң беренче—ата һәм ана өстендә булган бала хакы”,—ди. Бала хакы өчен ата һәм ана, яки алар урынында булган яклаучылар дөньяда да, Ахирәттә дә җаваплы булырлар. Шуның өчен бу хакларны белү һәм кирәк булганда җиренә җиткереп үтәү мәҗбүри.

Галим фикеренчә, бала һичбер орлык чәчелмәгән җир яки һичбер бизәк язылмаган ак кәгазь булып, нинди орлык чәчелсә, шуның кебек иген бирер һәм нәрсә язылса, шул укылыр. Әгәр балага гүзәл тәрбия бирелсә, ул изге, дөнья һәм ахирәттә бәхетле булыр. Әгәр балага бозык тәрбия бирелсә, яки хайваннар кебек каралмаган, ташланган булса, бичара бала да һәлак була, гөнаһысы да яклаучылар өстенә төшәр.

Балаларның бәхетле һәм гаиләнең рәхәт булуын теләгән ир белән хатын һәрвакытта бер сүздә булып, берләшеп һәм бер-берсенә хөрмәт белән торырга тиеш. Шулай булганда гына гаиләдә барлык кеше инсафлы була. Ике арада аз гына бер каршылык галәмәте күренә башласа, кичекмичә аны бетерергә керешергә кирәк.

## Кеше күрке— әдәп

- Мөселман һәр эшнең башында “Бисмилләһир-рахмәнир-рахим” дип әйтә.
- Мөселманннар очрашканда: “Әссәламегаләйкүм!”—дип әйтәләр һәм бер-берсенә елмаялар.
- Мөселман Аллаһ яраткан нәрсәләргә соклана һәм: “Сөбханаллаһ!”—ди.
- Мөселман һәрвакыт Аллаһыдан хәерле эшләр, бәхет-сәгадәт сорый, һәр теләгенең соңында: “Иншаллаһ”—ди.
- Мөселман Аллаһы Тәгаләгә барча нигъмәтләре өчен шөкер итеп: “Әлхәмдүлилләһ”—дип әйтә.




## “Шөкерле сәпит”

Рәсимә белән Рәсилә авылга кунакка кайттылар. Ишегалдындагы яшел чирәмдә рәхәтләнеп яланаяк йөрделәр, туп уйнадылар, сикерделәр. Икенче көнне Дәү әтиләре аларның икесенә дә велосипед алып кайтып бирде.

—Мәгез, балалар, рәхәтен күрегез,—диде ул, балалар кебек сөенеп.

Велосипед игезәкләрнең күптәнге хыялы иде. Сөенечтән башы әйләнгән Рәсилә, велосипедын өстерәп урамга чапты. Рәсимәнең дә түбәсе күккә тигән иде.

—Аллага шөкер, Дәү әтием, бик зур рәхмәт инде сиңа,—диде ул, велосипедын сыпыргалап.

Рәсимә дә урамга чыгып китте. Бер сәгать тә узмады, Рәсиләнең елаган тавышы ишетелде. Дәү әни белән Дәү әти: “Ни булды икән?”—дип уйларга да өлгермәде, капкадан игезәкләр кайтып керде. Ни көләргә, ни еларга белмәде олылар... Рәсиләнең велосипеды урталай аерылган иде.

—Ни булды, балалар?—дип аптырап сорады Дәү әни.

—Рәсиләнең сәпите белән Алмаз таудан төшкән иде, сынды,—дип мышкылдады Рәсимә.

—Алмазмы? 12 яшьлек малай утыра торган нәрсәме инде ул? Ник бирдегез?—дип эрләде Дәү әтиләре.

—Туктагыз әле,—диде Дәү әниләре.—Рәсилә рәхмәтен әйтмәде бит, тиз генә урамга чапты. Ә Рәсимә рәхмәтен дә әйтте, Аллага шөкер итеп куана да белде. Менә, күрдегезме инде, балалар? Булганына шөкер итә, Аллаһка рәхмәт әйтә белергә кирәк. Шөкер итә белсәң, әйберләрең бәрәкәте дә була.


Рәсилә башын иеп тыңлап торды да, велосипедын кызганып елап җибәрде.

—Елама, туганым, икебезгә берәү дә җитәр, Аллаһ боерса!—дип юатты аны Рәсимә.

Дөрестән дә, “Шөкерле сәпит” кызларга җәй буе ватылмыйча хезмәт итте.

**Мөнирә САФИНА**

## Рәсемне буя.





## “Иманлы Гаилә”не өеңә яздыр!

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Әссәламегаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә барча мактауларыбыз булсын, сез “Иманлы Гаилә” газетасының 2нче санын кулыгызга алдыгыз. Газетабыз күңелегезгә хуш килгәндер, үзегезне борчыган кайбер сорауларга җавап таба алгансыздыр дип ышанабыз.

Безнең максат—гаиләләргә булышу, яшь гаиләләрнең киләчәк бәхетле тормышларын төзүдә аңлату эшләре белән ярдәм итү, Ислам дине аша аларны тәрбияләү. Максатыбыз—изге, теләгебез—ихлас. Күргәнегезчә, газетабыз максатка ирешү юлында беренче адымнарын атлады инде. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән, үз укучысын тапты, фикердәшләр туплады һәм... “Иманлы Гаилә”не хәзер Татарстанның һәр районында яшәүче укый ала. Моның өчен газетага “2012 елның икенче яртыеллыгына” дип язылырга гына кирәк.

Барлык почта бүлекчәләрендә дә “Иманлы Гаилә” газетасына язылырга мөмкин. Эшегезне җиңеләйтү максатыннан, әзер квитанция тәкъдим итәбез. Аны кисеп алыгыз һәм почта бүлекчәсенә илтеп бирегез яки почтальоныгызга биреп җибәрегез. Газетага язылу бәясе—60 сум. Язылу индексы—**16062.**

Бергә булыйк!

---

**Ф.СП-1**

**АБОНЕМЕНТ на газету** **16062** (индекс издания)

**Иманлы Гаилә** (наименование издания)

количество комплектов:

на 20**12** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | x | x | x | x | x | x |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

ПВ | место | литер

на газету **16062** (индекс издания)

**Иманлы Гаилә** (наименование издания)

| Стоимость | подписки | **60** руб. **00** коп. | количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ____руб.____коп. | |

на 20**12** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | x | x | x | x | x | x |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

! **Игътибар!**

*Рус телле мөселманнар өчен “Крепкая семья” газетасы нәшер ителә. Әлеге газетага шулай ук Татарстанның барлык почта бүлекчәләрендә язылырга мөмкин. Индексы—16068. Язылу бәясе—60 сум.*

---

## Сездән—сорау, бездән—җавап

***Дини һәм көнкүреш мәсьәләләренә кагылышлы сораулар буенча белгечләрдән консультация алырга мөмкин.***

**Телефон: (843) 279-08-32.**
**Юридик консультация бирү бүлеге.**

**Кабул итү көннәре:**

**Шәүкәт хәзрәт ӘБҮБӘКЕРОВ.**
Дүшәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе көннәрендә 17.00-18.00 сәгатьләрдә.

**Адвокат Руслан НАГИЕВ.**
Сишәмбе, җомга көннәрендә 17.00-18.00 сәгатьләрдә.

### УЗГАН САНДАГЫ СКАНВОРД ҖАВАПЛАРЫ

**Горизонталь буенча:** Гакыйдә. Кыяр. Мәсех. Микат. Сукүн. Әни. Иман. Мөселман. Африка. Шәех. Мина. Җеназа. Фәнил. Иран. Нәни.
**Вертикаль буенча:** Сум. Шарф. Әби. Котүче. Хаҗи. Елан. Мизан. Гарәфә. Азан. Намаз. Мәми. Ихрам. Әти. Икс. Хатын. Аша.

## “КӨН ДӘ КИРӘКЛЕ ДОГАЛАР” КИТАБЫ ДӨНЬЯ КҮРДЕ




“Гаилә” нәшрияты тарафыннан төзелгән “Көн дә кирәкле догалар” китабы дөнья күрде. Һәр мөселман белергә тиешле Коръән сүрәләре һәм догалары тупланган рус телендәге басманың форматы бик уңайлы: аны кесәгә салып йөртергә дә, өстәл китабы итеп тотарга да мөмкин. www.islamsemya.ru сайтына кереп, китаптагы дога һәм сүрәләрнең дөрес әйтелешен тыңлый аласыз.

---

Газетаны www.islamsemya.ru сайтында укый аласыз.

Газета Татарстан Республикасы “Гаилә” Ислам-Мәдәни Үзәге” региональ җәмгыять оешмасы тарафыннан нәшер ителә.

www.islamsemya.ru
Телефон: (843) 279-08-32.
Тираж: 5000.

420088, Казан шәһәре,
2нче Азино урамы, 1В йорты.
Телефон/факс: (843)279-13-94
ИНН 1660163116 КПП 166001001
р/с №40703810200100000022
к/с 30101810900000000798
БИК 049205798
АКБ “БТА-Казань” (ОАО) г.Казань

Әлеге басманы нәшер итүдә катнашып, сез хәйрия эшләренә өлеш кертәсез